УДК 82-94

***А.Н. Хәсәнова***

# ӘДИП БЕЛӘН ОЧРАШУ

Настоящая статья представляет воспоминание Вали Нигматулловича Хангильдина (1891–1971) – известного ученого-языковеда – о его случайной встрече с классиком татарской литературы Фатихом Амирханом (1886–1926), состоявшейся в 1914 году в Казани. Оно написано в 1966 году и воспроизводит события, произошедшие во время пребывания Хангильдина в Казани на лечении. Посетив редакцию газеты «Кояш» (где одним из основателей и редакторов был его знакомый Закария Садретдинов), начинающий учитель из Уфы был представлен известному писателю и публицисту Ф. Амирхану. В беседе затронули актуальные вопросы женского образования и моды – яркие проявления джадидистских реформ в татарском обществе начала XX века.

Автор делится живыми личными впечатлениями, атмосферой интеллектуальной Казани 1914 года и характерными чертами личности Фатиха Амирхана, чья харизма и идеи заметно повлияли на формирование мировоззрения молодого Хангильдина. Воспоминание представляет собой ценный историко-литературный источник для исследователей татарской культуры начала XX века, обогащая понимание контекста творчества Ф. Амирхана и преемственности поколений.

**Ключевые слова:** Фатих Амирхан, Вали Хангильдин, татарская литература, воспоминания, Казань, Уфа, 1914, газета «Кояш»

The present article presents the recollection of Vali Nigmatullovich Khangildin (1891–1971) – an outstanding linguist – about his chance meeting with the classic of Tatar literature Fatih Amirkhan (1886-1926), held in Kazan in 1914. Recorded in 1966, this evidence was created during Khangildin’s stay in Kazan for treatment: having visited the editorial office of the Koyash newspaper (where one of the founders and editors was his friend Zakaria Sadretdinov), an aspiring teacher from Ufa was introduced to the famous writer and publicist F. Amirkhan. The conversation touched upon topical issues of women’s education and fashion – vivid manifestations of Jadidist reforms in Tatar society at the beginning of the 20th century.

The author shares lively personal impressions, the atmosphere of the intellectual Kazan of 1914 and the characteristic features of the personality of Fatih Amirkhan, whose charisma and ideas significantly influenced the formation of the worldview of the young Hangildin. The memory is a valuable historical and literary source for researchers of Tatar culture at the beginning of the 20th century, enriching the understanding of the context of F. Amirkhan’s work and the continuity of generations.

**Keywords:** Fatih Amirkhan, Vali Khangildin, Tatar literature, memoirs, Kazan, Ufa, 1914, Koyash newspaper

Быел киң җәмәгатьчелек татар әдәбияты классигы, язучы, публицист һәм тәнкыйтьче Фатих Мөхәммәтзариф улы Әмирханның тууына 140 ел тулуны билгеләп үтә.

XX йөз татар мәдәни тормышының үзәк фигурасы булган Ф. Әмирханның иҗаты, иҗтимагый эшчәнлеге һәрвакыт игътибар

үзәгендә булып килде. Аеруча иҗади мирасы әдәбият галимнәре тарафыннан төрле яссылыкта өйрәнелеп, шактый киң яктыртылды. Язучының иҗтимагый эшчәнлегенә һәм шәхси тормышына ачыклык кертүче чыганакларның берсе – аның турында замандашлары язып калдырган истәлекләр. Аларның төп өлеше әдип вафатыннан соң ук языла башлап, күбесенчә вакытлы матбугат битләрендә юбилей мөнәсәбәтләре белән басылып килә. 1986 елда, Ф. Әмирханның тууына 100 ел тулу уңае белән, Р. Әмирханов газета-журнал битләреннән, язучының архивыннан табылган истәлекләрне беренче тапкыр җыеп, китап итеп бастыра. Тулыландырылган икенче басмасы исә әдипнең тууына 120 ел тулу уңаеннан 2005 елда дөнья күрә, аңа төрле шәхси архивлардан табылган яңа истәлекләр дә кертелә.

Шунысы мөһим: вакытлар үтүгә карамастан, әдип турында кыйммәтле истәлекләр әле дә очрап тора. Мәсәлән, ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәгендә Вәли Нигъмәтулла улы Хангилдин фонды саклана. Анда быел тууына 135 ел тулган әлеге танылган лингвист, педагог, татар теленең фәнни грамматикасын булдыручы галимнең тормыш юлы һәм гыйльми эшчәнлегенә караган материаллардан тыш, 1959–1967 елларда замандашлары, күренекле әдипләр: Ш. Бабич, Г. Ибраһимов, Г. Алпаров, С. Сәйфуллин һ. б. турында язган истәлекләр дә урын алган. Шулар арасында Ф. Әмирхан турында кулъязма истәлек тә табылды (85 ф., 1 тасв., 113 сакл. бер.).

В. Хангилдин тарафыннан 1966 елда язылган әлеге истәлек – галимнең татар әдәбияты классигы Фатих Әмирхан белән булган тәүге очрашу мизгелен, аның белән аралашудан алган тәэсирләрен бәян итә һәм шул чорга кагылышлы милли-иҗтимагый вазгыятьне чагылдырган кыйммәтле тарихи документ булып тора. Ул татар мәдәниятен өйрәнүчеләр һәм сөючеләр өчен юбилей даталарына мөнәсәбәтле аеруча актуаль булыр дип ышанабыз.

## ОЧРАКЛЫ БЕР ОЧРАШУ (ФАТИХ ӘМИРХАН БЕЛӘН)

1914 елның җәе. Июньнең соңгы атнасы иде бугай. Сукыр эчәгем шешү авыруымнан арыну максаты белән Казанга сәфәр иттем: Казан больницаларында операция ясап, бу чирне төзәтәләр дигәннәр иде.

Пароходтан төшкәч, извозчик мине «Болгар»[1] исемле бер кунагөйгә[2] китереп кертте. Монда иң элек менә шушы тарихи бинада булдым, Габдулла Тукай торып үткән кунагөйне күрдем. Ул торган бүлмәне дә күрсәттеләр. Ләкин шагыйрь үзе бу чакта монда гына түгел,

[1] «Болгар» кунакханәсе – Октябрь инкыйлабына кадәр кунакханәдә татар мәдәниятенең күренекле вәкилләре яшәгән яки тукталган. Габдулла Тукай 1907–1913 елларда бирedә кунакханәнең 40 нчы бүлмәсендә яшәгән. Киров урамы белән Татарстан урамнары кисешкән чатта 14/19 нчы йортта урнашкан була.

[2] Кунагөй – кунакханә.

дөньяда ук юк иде, үзен күрү миңа насыйп булмады. Шунда эшләүчеләр аның турында бары тик кайбер эпизодлар гына сөйләделәр.<...>

Мин монда, Казанда, беренче тапкыр… Шәһәрнең үземне кызыксындырган урыннарын, беренче чиратта, татарлар яшәгән бистә һәм төбәкләрен күздән кичердем. Атаклы Кабан күле тирәләрен әйләндем, Болакны буйлап үттем. Ләкин, минем күземә иң нык ташланган урыннар «Печән базары»[1] һәм шуның тирәсендәге урамнар булды. Татарларның мондагы мыж килеп торган хәрәкәте, ыгы-зыгысы чыннан да ургылып, кайнап торган зур казанны күз алдына китерә иде. Г. Тукайның «Кисек баш»[2] исемле балладасындагы картина һәм һәртөрле образлар монда бөтенләй тере килеш минем күз алдымнан кичтеләр.

Монда чын искелек күренешләре арасында яңалык чаткылары да күзгә ачык чагылды. Яңалык күренешләре бигрәк тә татар телендәге нәшрият эшләрендә, китап сәүдәсендә һәм вакытлы матбугат төрләрендә минем күземә нык ташланды. Шуларга карап, ул чакта мин Казан татарларының Уфадагылардан гомумән, өстенлеге, культура һәм аңлылык якларыннан да алдынгылыгы турында бер нәтиҗәгә килә язган идем. Ләкин, күп тә үтмәстән, минем бу уемның өлешчә генә дөреслеге аңлашылды.

Казанда минем күз күргән таныш-белешләрем әле берничә генә иде. Болар арасында да мине санга алып, минем белән уртак сүз табардай якыннары тагын да азрак иде. Шуларның берсе – «Кояш»[3] газетасының редакторы Зәкәрия ага Мәрҗани (Садырттинов)[4] булды. Бу зат – Уфадагы «Галия» мәдрәсәсендә[5] укыткан зур белемле кешеләрнең (мөдәррисләрнең) берсе, минем дә укытучым булган кеше. Бер көнне, иртә белән, мин «Кояш» газетасы редакциясендә булдым. Зәкәрия ага белән беркадәр вакыт әңгәмәләшеп утырдык. Бераздан соң мин урынымнан кузгалып саубуллашмакчы идем, ул мине туктатты да: «Ашыкма, Казанга синең беренче килүең бит, Фатих белән таныш түгелдерсең, озакламый ул килергә тиеш, мин сине аның белән таныштырырмын, ул Уфадан килүчеләр белән әңгәмәләшергә бик ярата», – диде.

Мин аптырап калдым: башыма бөтенләй килмәгән бер яңа хәбәр!

---

[1] «Печән базары» – Татарстан урамының бер өлеше, Киров һәм Париж коммунасы урамнары кисешкән чатта урнашкан зур базар.

[2] «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» поэмасы (1908).

[3] «Кояш» – 1912 елның 10 декабреннән алып 1918 елның 24 июненә кадәр Казанда чыккан газета.

[4] Зәкәрия Садретдинов (? – ?) – педагог, журналист, «Кояш» газетасының мөхәррире һәм нашире (1912–1918). Шиһабетдин Мәрҗанинең бертуган энесе, мәгърифәтче, Ташкичү авылының имам-хатыйбы һәм мөдәррисе Садретдин әл-Мәрҗанинең улы. *(Истәлектә фамилиясе хаталы язылган.)*

[5] «Галия» мәдрәсәсе – XX йөз башында татарлар һәм башка төрки мөселманнарның иң эре мәгърифәт учакларының берсе. 1906 елның октябрь аенда Уфа шәһәрендә ачыла. Мәдрәсәне нигезләүче һәм алыштыргысыз җитәкчесе Зыя Камали була. Октябрь революциясеннән соң, 1919 елда, мәдрәсә ир балалар өчен икенче баскыч гомуми белем мәктәбе итеп үзгәртелә, 1920 елда ябыла.

– Кем соң ул Фатих? – дип соравыма Зәкәрия ага: «Фатих Әмирхан бездә эшли бит[1], озакламый килеп җитәр, күрерсең», – диде дә, өстәлендәге бер газетаны миңа сонып[2]: «Тик утырырга иренсәң, менә газетабызның бүгенге яңа санын караштыра тор», – диде.

Ләкин, күзләрем газетада булсалар да, минем уем Фатих Әмирхан турында иде. Матбугат һәм әдәбият буенча ул миңа да таныш, ә үзен күргәнем юк. Әсәрләрен укуым буенча, ул минем күз алдымда ничектер шактый кырыс, каты телле, шуграк бер кеше булып гәүдәләнә иде. Уйга калдым: «Мин соң андый кеше белән ничек сөйләшермен. Ул мине санга алырмы? Ул бит – танылган язучы, әдип, ә мин шәкертлектән әле генә чыгып килә торган бер укытучы – мөгаллим. Матбугат, әдәбият мәйданнары белән әле минем танышлыгым да бик чикле, аның сорауларына мин соң дөрес җавап бирә алырмынмы» һ. б. турында мин уйланып утырдым.

Шул арада кемдер: «Фатих абый килде», – дип эндәште. Өстәленә утырып, берничә минут үткәч, Зәкәрия ага, утырган урыныннан кузгалып, мине аңа тәкъдим итте: үзенең элекке шәкерте, хәзерге көндә мөгаллим булуым һәм Уфада эшләвем белән мине сыйфатлап, безне күрештерде.

Очрашу мин уйланып шомланганча авыр да, катлаулы да булмады. Фатих сүзне бик гади нәрсәләрдән, хәл-әхвәл сорашудан башлап җибәрде. Мин Казанга нинди максат белән килүемне һәм беренче тапкыр килүемне әйттем. Ул минем Казанда алган беренче тәэсирләрем белән кызыксынды. Монда тору һәм шәһәр белән танышу аралыгым бик кыска булганлыктан, күргәннәремнең кайбер моментларына карата гына мин аңа үз тәэсиремне белдерә алдым. Шуларга таянып, Казанда медицина эшләренең көчлелеген, татарлар арасында да нәшрият һәм матбугат эшләренең киң колач ала баруын чамалавым турында берничә сүз әйттем. Шуннан чыгып, Уфадагылар белән чагыштырганда, Казан татарларының гомуми аң һәм культура якларыннан да өстенрәк булулары ихтимал, дигән фикер белдердем.

Нәкъ менә шушы урында Фатих мине туктатып, сүзне үзе алды. Ул минем Казан турындагы фикерләремнең күбесе белән килешүен әйтте һәм медицина белән нәшрият, матбугат эшләренең зурлыгы турында үзеннән дә кайбер фактлар, мисаллар да өстәп куйды. Әмма Казан татарларының гомум аң һәм культура буенча Уфадагылардан өстенлеге турындагы фикерем белән ул килешмәде: «Аеруча, аңлылык ягыннан Уфа татарлары алдарак баралар», – диде ул. Шуны исбат итү өчен, берничә мисал да китерде. Иң элек, үткен күзләре белән миңа текәлеп карады да:

– Менә сезгә бер мисал. Сез әле укудан яңарак кына аерылган бер егет, мөгаллим. Шушы киемнәрегездә сез Уфа татарлары арасында иркенләп йөри аласыз, сезне беркем дә гаепләми (минем өстемдә

[1] 1912–1918 елларда Ф. Әмирхан «Кояш» газетасында җаваплы сәркатип вазифасын башкара.

[2] Сонып – сузып.

костюм, ак яка, галстук, башымда панама-эшләпә, һәммәсе дә җәдитчә иде). Бездә бит шәкерт һәм мөгаллимнәр татар ягында сезнеңчә киенеп йөри алмыйлар әле. Күрәсез, хөрмәтле мөхәрриребез Зәкәрия абзый да әле һаман казаки кия, – дип көлдерде һәм, өстәлендәге эшләпәгә кулы белән ишарә итеп: «Беләсезме, менә мондый эшләпәне Казанның татар ягында фәкать мин генә киеп йөрим. Печән базары яныннан үткәндә, мондый киемнәрем өчен миңа да көфер пичәте басып[1] калгалыйлар», – диде. Көлештек.

Аннары, Фатих Казан белән Уфада хатын-кызлар хәлен чагыштырып үтте: «Уфада бит хатын-кызлар йөреш-торышта һәм ирләр белән аралашу буенча үзләрен шактый иркен тоталар. Казанда исә әле безнең гимназисткаларыбыз да аңа ирешә алганнары юк, татар ягында алар йөзләрен ирләргә күрсәтә алмыйлар. Алай гына да түгел, Уфадагы кызлар мәктәпләрендә хәтта ир укытучылар-мөгаллимнәр дә укыта икән», – дигәч, Фатих миңа карап: «Дөресме?» – дип сорады.

Бу фактны мин һәм Зәкәрия ага – икебез дә расладык. Шуңа мин кызлар мәктәпләренең кайберсендә укытучы мөгаллим түгел, бәлки укучы кызларның үзләре күнегеп өлгермәү фактлары булганлыкны гына өстәп куйдым: «Укытучылар арасында таралган хәбәрләргә караганда, андый мәктәпләрдә укучы кызларның кайберләре, ир укытучы класска кергәч, йөзләрен шәлләре яки яулык почмаклары белән каплыйлар икән. Арада хәтта укытучыга аркасы белән борылып, артка таба карап утыра торганнары да очрый, дип сөйлиләр», – дидем.

Бергәләп көлештек. Безнең утырышыбыз да шуның белән тәмамланды. Бу минем Фатих Әмирхан белән очраклы бер очрашуым булды. Монда мин аның кырыс та, һавалы да түгел, бәлки башкаларга игътибарлы, мәраклы[2] һәм мөлаем бер кеше булуын аңладым.

*В. Хангилдин.*
*1966 ел.*

*Басмага әзерләде:*
***Хәсәнова Айгөл Наил кызы,***
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма мирас үзәге фәнни хезмәткәре*

*К печати подготовила:*
***Хасанова Айгуль Наиловна,***
*научный сотрудник Центра письменного наследия Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ*
*dream8708@mail.ru*

[1] Көфер пичәте сугу (басу), кара көфер мөһере сугу (басу) – динсез дигән мәгънәдә кулланылган. Көфер почмагы – Октябрь инкыйлабына кадәр Казанда, Печән базары мәчете янында, кадимче динчеләрнең җыелу урыны.

[2] Мәраклы – кызыксынучан.